РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
18.07.2024

**КАРАР**
№ 190 Бк/к

Буа шәһәре

«Яшь педагогларга ярдәм» стимуллаштыру түләүләрен билгеләүгә конкурс турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын кызыксындыру һәм бүләкләү максатларында, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июлендәге 207 Бк/к номерлы карары белән расланган «Яшь педагогларга ярдәм» стимуллаштыру түләүләрен бирүгә конкурс турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 1.4. пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Стимуллаштыручы түләүләр булып түбәндәгеләр тора:

- агымдагы елда югары уку йортын тәмамлаган һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яңа килгән яшь педагогларга бер мәртәбә 50 мең сум күләмендә түләү;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яшь педагогларга хезмәт хакына ай саен 5 мең сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә 1-4 елдан башлап хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яшь педагогларга конкурс буенча сайлап алу йомгаклары нигезендә хезмәт хакына бер тапкыр 20 мең сум күләмендә түләү.».

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.А. Македонскаяга йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов